# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Войкино авыл җирлеге составына керүче
Войкино авылы торак пунктында

2020 елның 10 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге составына керүче Войкино торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда Войкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
   - кышкы һәм җәйге чорда торак пунктларның юлларын төзекләндерү;
   - торак пункт урамнарын төзекләндерү һәм карап тоту;
   - Войкино авылы чишмәсен төзекләндерү;
   - су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту;
   - торак пунктларда урамнарны яктырту;
   - трактор тотуга чыгымнар.
3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Войкино авыл җирлеге башлыгы Н.П.Шәбетдинова